КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 апрель г.Казань № 421

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 858 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 858 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 октябрь, 1072 нче; 2022 ел, 7 декабрь, 1299 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

әлеге Тәртипнең кушымтасындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин